КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 15 май г.Казань № 399

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тукай муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2019 ел, 29 апрель, 355 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тукай муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында» 2019 ел, 29 апрель, 355 нче карарына, 1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Тукай муниципаль районы башкарма комитетының Тукай муниципаль районында урнашкан, дәүләт милкендә булган 15,7627 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчермәләрдә күрсәтелгән чикләрдә ритуаль эшчәнлек объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:39:141001:56 | 2,2192 |
| 16:39:141001:52 | 3,2966 |
| 16:39:141701:12 | 2,654 |
| 16:39:181301:153 | 2,2935 |
| 16:39:181101:48 | 2,5207 |

| | |
|---|---|
| 16:39:181001:99 | 0,7056 |
| 16:39:181001:95 | 2,0731 |
| Барлыгы | 15,7627.». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин